Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының
Данауровка авыл җирлегенең Данауровка авылындагы
гражданнар җыены

# КАРАР

## Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Данауровка авыл җирлеге составына керүче Данауровка авылындагы гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

2020 елның 22 ноябре №2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, «2021 елда Чистай муниципаль районының Данауровка авыл җирлегенең Данауровка авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, Бөек Ватан сугышы Ветераннарыннан, 1 төркем инвалидлардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкаруга җибәрү белән ризалашасызмы?» дигән сорау буенча 2020 елның 22 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

- Данауровка авылында Үзәк урамы буенча суүткәргеч челтәрләрне ремонтлау

« РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында 433 катнашучы кертелгән, җыенда катнашучылар саны 216 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«РИЗА» позициясе өчен гражданнар җыенының 181 катнашучысы тавыш бирде;

«КАРШЫ» позициясе өчен җыенда 35 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар итте:

1. Чистай муниципаль районының Данауровка авыл җирлегенең Данауровка авылындагы гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен - дөрес дип танырга.

2. «2021 елда Чистай муниципаль районының Данауровка авыл җирлегенең Данауровка авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, Бөек Ватан сугышы Ветераннарыннан, 1 төркем инвалидлардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкаруга җибәрү белән ризалашасызмы?» дигән сорау буенча карарны кабул ителгән дип танырга:

- Данауровка авылында Үзәк урамы буенча суүткәргеч челтәрләрне ремонтлау.

3. Чистай муниципаль районының Данауровка авыл җирлегенең Данауровка авылы территориясендә 2021 елда үзара салымны, Чистай муниципаль районының Данауровка авыл җирлегенең Данауровка авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, Бөек Ватан сугышы

Ветераннарыннан, 1 төркем инвалидлардан тыш, 500 сум күләмендә кертергә, һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- Данауровка авылында Үзәк урамы буенча суүткәргеч челтәрләрне ремонтлау.

4. Әлеге карарны авыл җирлегендә яшәүчеләрне күпләп җыелган урыннарда, игълан итү стендларында һәм такталарында элеп чыгу юлы белән игълан итәргә, шулай ук Чистай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Халык җыенында рәислек итүче,
Данауровка авыл җирлеге
башлыгы _________________ В.К. Сәдретдинова